**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **26 ноябрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Әсәй авылында 2021 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2021 елда Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Әсәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Әсәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әсәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Әсәй авылы урамнарына вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, билгеләр кую, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру (Әсәй авылы зиратларында контейнерларга каты өслек урнаштыру, чүп-чар өчен контейнерлар сатып алу);
- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авылы, Үзәк ур.,38Б йорт;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авылы Елга Аръягы ур., 27 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Әсәй  авылы,  Үзәк  ур., 60 йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы                                                    Идрисов З.Ә.